РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
ЧЕРКИ-КИЛЬДУРАЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

РЕШЕНИЕ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДУРАЗ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

КАРАР

18.03.2026 № 1-12

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 елгы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 25.12.2008 елгы 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип таныргa:

- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирелгән белешмәләр бирү тәртибен раслау хакында» 2017 елның 09 сентябрендәге 37-1 номерлы карары.

- «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары

тарафыннан бастырып чыгару өчен  Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирелгән белешмәләр бирү тәртибенә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге Советының 2017 елның 09 сентябрендәге 37-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 25 июнендәге 2-22 номерлы карары.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районының
Килдураз авыл җирлеге башлыгы
З.З.Әхәтов